ISSN 0868-4545



Сабантуй купере



Кичә-бүген заманда

(Татарстан Дәүләт Советы депутаты, М.Җәлил исемендәге мәртәбәле бүләк иясе, шагыйрь Разил Исмәгыйль улы Вәлиевнең шигъри дөньясына бер күңелле сәяхәт)

Борын-борын заманда түгел, кичә-бүген заманда яшәгән ди, яши ди укымышлы бер малай. Өстәвенә үзе эшчән, үзе хисчән, укуда да, уенда да өлгер-җитез булган ди ул. Исем-аты Разил икән. Укымышлы малай булгач, китапларны бик яраткан. Китапларны гына түгел, туган авылы Ташлыкны да, аның күркәм кешеләрен дә, гүзәл-серле табигатен дә һәм, әлбәттә (һәм, әлбәттә!), кадерле вә газиз әти-әнисен дә бик-бик яраткан икән Разил. Яратуы гамьле уйлар, шигъри юллар булып ак кәгазь битләренә дә күчкән:



Ашкын җилләр юлга дәшә,
Ялы тузгый колынның.
Тал кызлары, ярга ятып,
Юа яшел толымын.
«Хуш киләсез!» – дигән кебек,
Тиен җиргә сикерә.
...Мин бәхетле, Туган ягым,
Сине сөйгәнгә күрә.

Шулай итеп, көннәрдән бер көнне авылда, тирә-юньдә «Шагыйрь!» дигән даны таралган малайның...

© "Салават күпере", 2004 ел

яши икән бер малай...



Көннәр үткән, айлар үткән, еллар арты еллар үткән... Инде хәзер шагыйрь Малай Шагыйрь Абый булып үсеп җиткән. Илләр буйлап сәяхәттә йөргән, мавыктыргыч китаплары бер-бер артлы дөнья күргән. Онытмаган сабыйларны, апаларны-абыйларны: алар өчен шигырьләр һәм җырлар язган, ул шигырьләр һәм җырулар халык күңелендә урын алган. Шагыйрь Абый менә шулай гомер иткән, иҗат иткән һәм хәзер дә «Халкым!» диеп, милләт өчен борчылып вә янып-көеп яши шулай. Инде хәзер Шагыйрь Абыйның тормышы һәм иҗат юлы белән танышып алу бик мәслихәт бугай:

Разил абый Вәлиев 1947 елның 4 гыйнварендa Татарстанның Түбән Кама районы Ташлык авылында туа.

Түбән Камада урта белем алгач, 1965 елда Казан дәүләт университетына укырга керә. Икенче курстан Мәскәүдәге М.Горький исемендәге әдәбият институтына күчә.

1972-1981 елларда «Ялкын» журналы редакциясендә эшли, Татарстан Язучылар берлегенең башта Чаллы шәһәре оешмасында җаваплы секретарь, аннары берлек идарәсе рәисе урынбасары итеп сайлана.

«Зәңгәр кабырчыклар» исемле беренче шигъри китабы 1971 елда дөнья күрә.

Бүгенге көндә ул – берничә дистә китап авторы.

1982 елда «Яшисе килә» дигән повесте һәм популяр җырлары өчен М.Җәлил исемендәге мәртәбәле бүләккә лаек була.

1979 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы.

1990 елдан Татарстан Дәүләт Советы депутаты.

Сезнең кебек чакта Разил атлы малай да балык тотарга яраткан, көтү көткән... Көтү көтү дигәннән, көтүнең дә әле ниндиен көткән ул – кәҗә көткән! Вәйт!

Көтүче

(Рөстәм Кутуйдан)


Мин – көтүче. Кәҗә көтәм,
Кулда – чыбыркы.
Чыбыркы тоткан беләкләр
Җаен чыныкты.

Сикерә дә менеп китә
Кәҗә гел өскә,
Коймаларны бәреп керә,
Күрсә кәбестә.

Мин – көтүче, солдат кебек
Һәрвакыт сакта.
Көне буе чаба торгач,
Кичкә аксата.

Тәмле була, татлы була
Чык төшкән үлән...
Ә кичләрен сыйланам мин
Җылы сөт белән.

Кәҗә көтәм. Үзем көтәм
Еллар үтүен.
Үсеп җиткәч, тапшырырлар
Сыер көтүен.



Беләсезме, көтү көтеп, арып кайткач, малайлар өйдә нишлиләр? Әлбәттә, башта әниләре пешергән тәмле-тәмле ризыкларны ашыйлар. Тамаклары туйгач, әниләренә рәхмәт әйтеп, телевизор карарга... юк ла инде... әкиятләр укырга тотыналар.



Төнге әкият

(Рөстәм Кутуйдан)

Карурманда бер йорт бар,
Колаклары – әрекмән...
Яши анда бер карчык,
Белмәгәне юк икән!

Өе тулы сер аның:
Кем елаган, кем көлгән,
Кем адашкан урманда,
Кайда яфрак селкенгән...

Аш пешерә, чәй куя,
Түрдә шүрәле ята.
Кичен бии башлыйлар,
Аш һәм ботка ашыйлар,

Учак ягып гөрлиләр,
Утырмага йөрмиләр.

Шүрәле казан асты,
Кунак килеп чыкмасмы? –
Су анасы, Йорт иясе
Ярата идән астын.

Дуслары күп урманда,
Куян, кош-корт бар анда.

Бик ямансу чакларда
Бара алар – уты сүнгән,
Балалар йокыга түнгән
Тәрәз төбен сакларга.

Шык-шык тәрәзә чиртәләр,
Аннан кайтып китәләр...
Әби белән карт шүрәле
Ялгыз гомер итәләр.

Карурманда бер йорт бар,
Колаклары әрекмән.
Явыз карчык һәм шүрәле
Шул йортта яши икән...



Кызык икән ул, әй! Шәһәрдән туган авылларын сагынып кайткан абый-апаларның сөйләгәннәрен ишеткәнегез бардыр:

– Бәләкәй чакта, әти-әнинең иркәләвен-назын тоеп яшәгәндә, дус-ишләр белән шау-гөр килеп уйнап йөргәндә сагынуның ни икәне ике ятып бер төшеңә керми. Ә менә шәһәргә киткәч... Олыгайгач... Үтереп сагындыра икән авыл, аның гүзәл табигате! – диләр.

Шагыйрь Разил абый Вәлиев тә сагынадыр туган авылын. Ул да шәһәрдә, Казанда яши бит! Сагынадыр... Әле төшләренә дә керәдер... Сагынмаса, табигатьнең үзе кебек шундый гүзәл шигырьләрен язар иде микән Разил абый?!



Урман иясе

(Рөстәм Кутуйдан)

Агач төбендә
Урман иясе,
Кулында – кишер,
Куян диярсең...

Күзгә яшь килә,
Аптырап торам, –
Кайда чытырман,
Кайда карурман?

Чыжлый пычкылар,
Күмеп җир ямен...
Кайда чикләвек,
Кайда җиләгем?

Кайларга качыйм
Мотор шавыннан?
Җил булып елый,
Сыкрый карурман.

Урман иясе
Утырган төпне
Бульдозер сөреп
Таптатып үтте.

Башыннан сыйпап
Килә сөясем, –
Табыгыз качкан
Урман иясен!

Урманда

Җәйге урман – гөлләр иле,
Чәчәкләр патшалыгы.
Кызыл җиләк булып пешә
Урманның һәр шатлыгы.

Усал булсаң, ул да усал:
Һәрбер ботагы – камчы.
Ә дус булсаң, кочак ала
Урманның һәр агачы.





Шагыйрь абый печән чаба дисәнә...
1997 ел, июль.



Таң

(Х.Шировтан)

Зәңгәр яулык япкан иртә
Йокысыннан уянды.
Ул күзләрен ачу белән,
Алланып офык янды.

Һәм ул күрде шаян җилнең
Агачны уятканын,
Тулган Айның тау артында
Югалганын, батканын.

Аннан күрде юынганын
Чык белән үләннәрнең
Һәм ишетте чәчәкләрнең
Чылтырап көлгәннәрен.

Тыңлады ул тыпылдавын
Иң соңгы тамчыларның,
Кояш алтын кулы белән
Тәрәзә шакыганын.

...Таң күргәннең бөтенесен
Үз күзем белән күрдем –
Чөнки бүген, иртүк торып,
Болында уйнап йөрдем.

Шагыйрьләрне һәркайда көтеп алалар: мәктәпләрдә, балалар бакчаларында... шагыйрьләрне төрле бәйрәмнәргә чакыралар... Алар анда нишлиләр дисезме? Әлбәттә, үзләренең әсәрләрен укыйлар, балалар белән гәпләшәләр, аларны кызыксындырган сорауларга җаваплар бирәләр, китаплар бүләк итәләр...

Әнә, Разил абый шигырьләрен укый да башлады инде...



Без – кояш балалары

Туган якта куәт җыйгач,
Китәрбез әле ары.
Күзләр күктә, әйтерсең без
Очар кош балалары.

Күңелләр – ярсу дулкындай,
Күренми хәтта яры.
Диңгезгә җитми тынмабыз,
Без – Идел балалары.

Җирдә туып үссәк тә без,
Хыяллар гел югары.
Алсу битләр – ал кояштай,
Без – кояш балалары!

Ни өчен?

Барысын беләм:
Кыш – чана шуар өчен,
Җәй – бәпкә куар өчен,
Яз – көймә ясар өчен,
Көз – алма ашар өчен,
Су – тәнне пакьләр өчен,
Ай – җирне саклар өчен...
Тагын, тагын әллә ниләр
Әллә нәрсәләр өчен...
«Дүрт»ле белән «биш»ле алу
Әни яратсын өчен.
Белмим менә «ике»леләр
һәм «бер»леләр ни өчен?

Кызык, Шагыйрь Абый «ике»леләр һәм «бер»леләрнең ни өчен икәнен белми. Ә сез беләсезме, дуслар?



Кырымда, Шагыйрь Абый янәшәсендә.



Шагыйрь Абый автографлар өләшә.



Шагыйрь Абыйның үз кулыннан бүләк алуы күңелле икән ул!



«Без барыбыз да – балачак иленнән»

Француз язучысы, очучы, «Нәни принц» дигән атаклы әсәрнең авторы Антуан де Сент-Экзюпери кайчандыр шулай дип әйткән. Сүз уңаеннан әйтик, «Нәни принц»ны татарча сөйләштерүче – Разил абыегыз Вәлиев. Әйе, чыннан да, без барыбыз да – сабыйчак иленнән. Шуңа дә өлкәннәр балачак илен һәрвакыт сагынып яшиләр. Сез дә, үскәч, әлбәттә, балачагыгызны сагынырсыз. Сагынмыйча мөмкин түгел... Шагыйрь булганнарыгыз, Разил абый шикелле, сагынуын шигырь итеп ак кәгазьгә төшерер...

Сеңелем

Аша, дисәң, ашамый,
Кашыгын атып бәрә.
Ачулансаң, тыңламый,
Тагын елап җибәрә.

Утыр, дисәң, утырмый,
Эшлә, дисәң, эшләми,
Урын җыймый, бит юмый,
Чистартмый ул тешләрен.

Ләкин аның турында
Чыгара күрмә гайбәт.
Көндез генә начар ул,
Йоклаганда бик әйбәт.


Минеке

Кычкыралар, сугышалар –
Әйтерсең, мәхшәр купты.
Ике малай бүлә алмый
Түп-түгәрәк бер тупны.

Берсе әйтә: «Минеке!» – ди,
Икенчесе: «Минеке!»
Шулай тарткалаша торгач,
Ярты көннәре үтте.

Әтиләре чыккан иде –
Әтәчлекләре очты.
«Минеке» дә «минеке» дип,
Тарталар хәзер пычкы.





Курыкмыйм

Сыртына капчыклап
Маймыллар төягән, –
Шулай да барыбер
Курыкмыйм дөядән.

Курыкмыйм жирафтан,
Курыкмыйм җилләрдән.
Фил борын күтәрсә,
Мин көлеп җибәрәм.

Әнием шаярта:
«Әгәр, – ди, – карышсаң,
Тотар да йотар, – ди, –
Менә бу арслан».

Тамчы да курыкмыйм!
Әйтегез, кем курка?
Бергәләп барырбыз
Иртәгә циркка.

Барысын да яратам

Кинога барган чакта
Әтиемне яратам.
Тәмләп-тәмләп ашаганда
Әниемне яратам.
Абыемны ачуланса,
Мин апамны яратам.
Дәрес хәзерләгән чакта
Абыемны яратам.
Күрше малае кыйнаса,
Әбиемне яратам.
Әкият сөйләгән чагында
Мин бабамны яратам.
Өйгә озак кайтмый торсам,
Барысын да яратам.



Шагыйрь Абый гаиләсе

Максат

Җир гизәрсең,
Йөрәгеңдә саклап
Илгә биргән антың.
Кабызырсың
Домна мичләрендә,
Мартеннарда ялкын.

Зәңгәр күктә,
Гел үзенә дәшеп,
Якты йолдыз балкыр.
Ракеталар
Алып китәр сине –
Сызылып калыр ялкын.

Киләчәктә,
Түрдән урын биреп,
Данга күмәр халкың.
Күңелеңдә
Булса
Ил кабызган
Мәңге сүнмәс ялкын.




Гармунлы яшьлегем истәлеге.



Оныгым – татлым минем.



Шагыйрь Абыйның кадерлеләре.



Бер оныгым зур инде.

Ярата икән әни


Әниләр уйлый һәрвакыт
Балам яхшы булсын, дип.
Ничек яхшы булырга соң?
Йөрим әле ымсынып.

Акыллы бул, яхшы укы,
Олыла икән дәүне.
Үз халкыңа дан китерсәң,
Ярата икән әни.





Шагыйрь Абый яшьтәше шагыйрь Зөлфәт белән.



Мин – яшьтәше атом бомбасының

Мин – яшьтәше атом бомбасының,
Мин мәңгелек уйда утырам.
Галимнәр, сез бомба ясаганда,
Әниләр бит безне тудырган.

Безгә күптән акыл теше чыкты...
Акыл кердеме соң аларга?
Матдәләрнең җанын суыра-суыра,
Галимнәрнең чәче агара.

Илләр бүләр өчен атом бүлеп,
Сак йокысын бүлеп кешенең,
Бәхеткәме, ләхеткәме икән,
Тарих, безгә юллар түшәдең?

Җәй җиттисә, шомлы күк күкрәде,
Без яшенгә кушылып яшьнәдек.
Мин – яшьтәше атом бомбасының, –
Икәү бергә чакта яшәү юк!



Шагыйрь Абый – сабыйчакта кунакта.



Шагыйрь Абый авыл агайлары белән бергә дога кыла.



Шагыйрь Абый остазлары-каләмдәшләре белән. Утырганнар (сулдан уңга): Әбрар Кәримуллин, Мөхәммәт Мәһдиев; басканнар – Нил Юзеев, Равил Фәйзуллин, Миркасыйм Госманов, Разил Вәлиев.





Миллəтпəрварлəр: Рабит Батулла, Разил Вəлиев, Илһам Шакиров, Туфан Миңнуллин, Гəрəй Рəхим.



Сагыну

Җыр-моң белəн татарны берлəштергəн бөек якташым Илһам Шакировка

Таныш ярлар, якын ярлар, туган җир –
Уйна да көл, шатлан, сөен, җырлап йөр.
Качкан күптəн моннан дошман яулары.
Шуңа горур, шуңа мəгърур таулары.
Туган җирдə безгə һəрчак кадер бар...
Адым саен монда таныш каберлəр.
Үткəннəрдəн калган сагыш-истəлек.
Бу сагышлар тормасачы өстəлеп.
Җылырак шул туган якның кояшы.
Монда безнең юл азагы, юл башы.
Чакыра тик ерак чүллəр, Себерлəр...
Тимер булды эштəн безнең сеңерлəр.
Җылынды күк хəтта Себер кояшы.
Тик туган як – һаман хəтер юлдашы.
Гөлгə күмдек ач даланы, чүллəрне.
Безнең тирдəн тозланды ил күллəре.
Җылытсак та салкын Себер җиллəрен,
Кошлар монда мəңгегə дип килмəде.
Хушлашканда əйтте безгə гел алар:
Көтə, диеп, безне анда оялар.
Дəртлəнеп без тагын эшкə тотындык.
Кайтырбыз без салкын Себер гөл булгач...
Сагышыңнан үлə күрмə, сандугач.
Ə хəзергə ташка тамсын кайнар тир...
Түз, егет бул, «Туган як», дип җырлап йөр.



Шагыйрь Абый композитор
Резеда Ахиярова белән.

Кайтчы, Сөембикә

Разил Вәлиев шигыре,
Резеда Ахиярова көе.

Казаныма төннәр иңсә,
Сине эзләп карыйм күккә.
Зәңгәр күктә ай моңлана,
Моңлана күк Сөембикә.

Ай моңлана зәңгәр күктә,
Казан һаман сине көтә.
Язмышыма хуҗа булып,
Кайтчы, зинһар, Сөембикә.

Сине уйлап көендек тә,
Сине уйлап сөендек тә.
Манарадан күңелемә
Сикергәнсең, Сөембикә.

Сагышларны сүтә-сүтә,
Айлар үтә, еллар үтә.
Безнең язмыш синең белән
Мәңге бергә, Сөембикә.









Татарстан Президенты Минтимер Шәрип улы Шәймиев һәм Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Хәйрулла улы Мөхәммәтшин белән.

Ватаным

Инде мин ничәнче мәртәбә
Гасырлар китабын актардым.
Күпме яу, сугышлар аркылы
Син җиңеп чыккансың, Ватаным.

Сез кайсы халыктан? – дисәләр,
Батырлар исемен атадым.
Батырлар утларга керделәр,
Тик исән булсын, дип, Ватаным.

Илемнең хуҗасы булганга,
Мин җиргә нык басып атладым.
Кешеләр күтәрде Ватанны,
Кешене күтәрде Ватаным.

Мин күрдем, төннәрне таратып,
Дөньяда алсу таң атканын.
Яктыра, аллана җир йөзе...
Таң булып нур сибә Ватаным.

Бу сандагы рәсемнәрне рәссам Фәрит МУЛЛАХМӘТ ясады.

Җырларым

Юлларым, юлларым, юлларым,
Юлларым уралган буранга.
Уйларым, уйларым, уйларым...
Кагылма ярама, сорама.

Кырларым, кырларым, кырларым,
Кырларым шатлыгы – тургайлы.
Урманым, урманым, урманым...
Ул миңа гел бәхет юрады.

Инешем, ак чишмәм, тауларым,
Талларым, кырларым, кошларым!
Мин сездә күпме җәй җәйләдем,
Мин сездә күпме кыш кышладым.



Мин киттем. Калдыгыз, калдыгыз...
Юлларым, иң якын дусларым!
Ә хәзер йортым да, юлым да –
Җырларым, җырларым, җырларым.



Салават күпере

7(172) — 2004

ЖУРНАЛНЫ ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ: ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЖИР, МИЛЕК МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ ИДАРӘСЕ һӘМ РЕДАКЦИЯ КОЛЛЕКТИВЫ.
1990 елның март аеннан бирле чыга.

УЧРЕДИТЕЛИ: МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РТ, ПРАВЛЕНИЕ СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ РТ И КОЛЛЕКТИВ РЕДАКЦИИ.
Основан в 1990 году.
На татарском языке.

Татарстан Республикасы Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы тарафыннан 96 нчы номер белән теркәлде.

Баш мөхәррир
Зиннур ХӨСНИЯР

Баш мөхәррир урынбасары
Вакыйф НУРИЕВ

Җаваплы сәркатип
Ләбиб ЛЕРОН

Бизәлеш мөхәррире
Фәрит МУЛЛАХМӘТ

Компьютер дизайны
Фидель ХӘСӘНОВ

Исәп-хисап бүлеге
Рәмзия САЛИХ

Тышлыкта Лилия ЗОЛОНДИНОВА рәсеме,

Мәктәпкәчә яшьтәге һәм кече яшьтәге мәктәп балалары өчен.

Адрес редакции:
420012 г. Казань, ул. Муштари, 14.
E-mail: ck-sxn@newmail.ru

«Салават күпере» журналының компьютер үзәгендә җыелды һәм төсләргә бүленде.

«Идел-пресс» полиграфия нәшрият комплексы» дәүләт унитар предприятиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

Производствога бирелде 23.06.2004 ел.
Басарга кул куелды 23.06.2004 ел.
Кәгазь форматы 60x100 1/8.
Гарнитура – Прагматика.
Офсет ысулы белән басыла.
Тиражы 12801 данә. Заказ Э-446.

Бәясе килешү буенча
Индекс 73953

Разил Вәлиев

Гармун

(Рөстәм Кутуйдан)

Кичә иске гармун таптым
Үзебезнең чормадан.
«Тимә аңа, – диде әби, –
Әй, кулың тик тормаган!

Күрәсеңме, картайган ул,
Тавышы да карлыккан.
Ничек шәп биетә иде –
Сора бөтен халыктан...

Бабаңны көтте сугыштан...
Бир гармунны, бир, улым.
Син бүтәне белән уйна –
Менә – синең гармуның».

